| «Рассмотрено»<br>Руководитель ШМО<br>____________/ Архипова Т.С./<br>Протокол № _____<br>от «__»__________201__г. | «Согласовано»<br>Заместитель директора по УВР<br>____________/ Архипова Ю.Л./<br>«__»___________201___г. | «Утверждаю» Директор<br>МБОУ «Тюгеевская ООШ»<br>_______________/Р.А.Бикташев /<br>Приказ № ______<br>от «__»_____________201___г. |
|---|---|---|

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**Учебного предмета**

# Татарский язык

МБОУ «Тюгеевская основная общеобразовательная школа»
Заинского муниципального района Республики Татарстан

# 5 класс

Учитель: Чекашова Галина Федоровна

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № ___________
от «__»___________201_ г.

2016-2017 учебный год

## 1. 5-9 нчы сыйныфның рус төркеме өчен татар теле дәресләренә төзелгән эш программасы паспорты

**Сыйныфлар – V-IX**
Укытучы – Чекшова Г.Ф.
Сәгатьләр саны:
Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен Зәй муниципаль районы Төги төп гомуми белем бирү баскычында татар теле предметын укытуга 488 сәгать билгеләнә. Һәр сыйныфта сәгатьләр саны бүленеше күрсәтелә:
V сыйныф – 3 сәгать – 105 сәгать;
VI сыйныф – 4 сәгать – 140 сәгать;
VII сыйныф – 2 сәгать – 70 сәгать;
VIII сыйныф – 2 сәгать – 70 сәгать;
IX сыйныф – 3 сәгать – 102 сәгать.

**Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:**

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

- Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында" №12138/13 ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының информацион хаты.

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2014 нче елда бастырылган "Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы 1 — 11 нче сыйныфлар". Төзүче авторлары Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева. (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2014)
- Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының "Төги төп гомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең башлангыч гомуми белем өчен төп белем программасы
- ТР Зәй муниципаль районы Төги төп гомуми белем мәктәбенең 2015-2020 нче уку елына уку планы.
- ТР Зәй муниципаль районы Төги төп гомуми белем мәктәбенең эш программаларын төзү буенча карары

## 2. Аңлатма язуы

"Татар теле " курсының эш программасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “төп гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”, (төзүче-авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. - Казан, 2014.), 5 нче сыйныф өчен Р.З.Хәйдарова тарафыннан эшләнгән (Казан: “Татармультфильм”, 2014.) Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде.

### Укыту предметына гомуми характеристика

Рус телендә сөйләшүче укучыларга татар телен дәүләт теле буларак укытуның төп максаты - телне аралашу чарасы буларак узләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру. Татар телен дәүләт теле буларак укыту укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру чарасы, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсаль күнекмәләр булдыру чарасы.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле фәнен укытуның максатлары:**

-укучыларның аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып,сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау,уку,язу) буенча укучыларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру;

- укучының танып белу мөмкинлекләрен ,гомуми уку күнекмәләрен ,сөйләм культурасын үстерү;

-татар милләтенә, аның тарихи һәм әдәбит хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; укучыларны мәдәниара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру, рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның бурычлары:**

- укучыларның аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда *коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы)*формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү;
- укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру;
- башлангыч гомуми белем бирү баскычы программасы белән дәвамчанлыкны саклау;
- укыту процессы коммуникатив методның төп принципларын исәпкә алып оештыру: *аралашуга аралашу аша өйрәтү принцибы* (телгә өйрәтү шартларын тормышта телне куллану шартларына якынлаштыру); *шәхси индивидуальләштерү принцибы* (укыту процессын

укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк- омтылышларын, индивидуаль-психик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру); *телне актив фикерләү нигезендә өйрәнү принцибы* (аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль куллануын тәэмин итү); *телне функциональ төстә өйрәнү принцибы* (лексик-грамматик материалның коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнүе);

- рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен укытуны аларның коммуникатив культурасын үстерүгә юнәлтү.

**Укыту предметы эчтәлегенең кыйммәтенә төшенү тасвирламасы:**

*Программаны үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар түбәндәгеләрне өйрәнә:*

- Россия Федерациясендәге телләр һәм мәдәниятләрнең күп төрле булуы турында башлангыч мәгълүмат ала, телнең милли үзаңны белдерүгә нигез булуын күзаллый;
- телнең милли мәдәни күренеш һәм аралашу чарасы булуына төшенә, рус теленең Россия Федерациясендә дәүләт теле буларак тоткан урынын һәм аның төрле милләтләр арасында аралашу чарасы булуын аңлый;
- укучыларда телдән һәм язма сөйләмне дөрес итеп төзүгә уңай караш тәрбияләнә, алар аны шәхеснең тәрбияле булу билгесе итеп кабул итә;
- татар телендә башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерә, аралашуның максат һәм бурычларыннан чыгып, тиешле тел берәмлекләреннән урынлы итеп файдалана белә.

*Рус мәктәбендә укучы рус балаларына татар теле укыту түбәндәге нәтиҗәләргә китерә:*

- Россия Федерациясе һәм аның төрле регионнарының тел һәм мәдәният ягыннан бердәм һәм күп төрле булуы турында башлангыч мәгълүмат бирелә;
- укучылар телнең милли мәдәнияткә каравын, аның төп аралашу чарасы булуын аңлый;
- әдәби нормаларга туры килгән телдән һәм язма сөйләмгә ия булган кешегә уңай мөнәсәбәт тәрбияләнә, аның культуралы шәхес булуы аңлатыла;
- татар теленең орфоэпик, лексик, грамматик нормалары һәм сөйләм әдәбе турында башлангыч мәгълүмат бирелә, аралашу өчен кирәкле тел материалын сайлап кулланырга өйрәтә;
- татар теле буенча алган белемнәрне укучы танып-белү һәм аралашу өчен тиешенчә куллана белә.

**Укытуның предмет, шәхси, метапредмет нәтиҗәләре.**

Федераль дәүләт белем стандартларында белем бирү системасының төп юнәлеше – системалы- эшчәнлекле юнәлеш, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент- нәтиҗә : шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнә.

***Укытуның предмет нәтиҗәләре.***

Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, рус телле укучылар татар теленнән түбәндәге предмет нәтиҗәләренә ия булырга тиеш:

-коммуникатив компетенциягә(аралашу осталыгына) ия булу, ягъни татар телендә телдән яки язмача аралашу күнекмәләрен үзләштерү;

-коммуникатив бурычлар куя һәм аларны хәл итә белү, аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан , сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;

-“Татар теле” фәнен өйрәнүгә карата уңай омтылышта булу, татар теле белән даимии кызыксыну һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерү.

***Укытуның шәхси нәтиҗәләре:***

Төп белем бирү мәктәбен тәмамлаганда, укучының үзенә карата һәм әйләнә – тирәдәге кешеләргә, яшәеш проблемаларына карата түбәндәге шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана:

шәхесара һәм мәдәният ара аралашуда татар теленә карата ихтирам.

- регулятив универсаль уку гамәлләре:

-эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү, эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү, билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирү, кирәкле төзәтмәләр кертү, үз эшчәнлегең белән идарә итү.

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

- аңлап уку, эчтәлекне үз сүзләрең белән сөйли белү, тиешле мәгълүматны табу; билгеләү; логик тәртипкә салу; мәсьәләне чишү йчен уңайлы ысул сайлау; төп һәм ярдәмче билгеләрне аеру, анализлау , объектларны чагыштыру, классификацияләү, чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру.

- коммуникатив универсаль уку гамәлләре:- коммуникатив мәсьәләдән чыгып, фикерне төгәл итеп җиткерү; әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү, әңгәмәдәшеңнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү.

## Укыту предметының укыту планында тоткан урыны

Татарстан Республикасы мәктәпләре өчен төп гомуми белем бирү баскычында татар теле предметын укытуга 488 сәгать билгеләнә. Һәр сыйныфта сәгатьләр саны бүленеше күрсәтелә:

V сыйныф – 3 сәгать – 105 сәгать;

VI сыйныф – 3 сәгать – 105 сәгать;

VII сыйныф – 3 сәгать – 105 сәгать;

VIII сыйныф – 3 сәгать – 105 сәгать;

IX сыйныф – 2 сәгать – 68 сәгать.

**Программа эчтәлеге.**
**5 нче сыйныф (105 сәг.)**

| **Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны** | **Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат** |
|---|---|
| **Без мәктәптә (27сәг.)**<br>Дәресләр расписаниесе, дәресләр әзерләү, өй эше эшләү. Билгеләр. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә, саклап тоту. Китапханәдә. | Уку-язу әсбапларының барлыгын, юклыгын, санын, кирәклеген хәбәр итә белү (сорау), үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкдим итә белү. Беренче сентябрь–Белем бәйрәме турында сөйли белү. Дәресләр расписаниесе буенча нәрсә эшдәгәнне әйтә белү. Өй эшен әзерләү, әзерләмәүнең сәбәбен әйтә белү. Ни өчен яхшы, начар билгеләр алу турында сөйләшү.Уку-язу әсбаплары, аларны саклап тоту турында киңәш бирә белү. Китапханәчедән кирәкле китапларны сорап ала белү. |
| **Мин – өйдә булышчы. (35сәг.)**<br>Без әти-әнигә булышабыз. Өйдәге эшләр. Без бергә эшлибез. Өй хезмәте өчен рәхмәт белдерү һәм мактау. Кем эшләми - шул ашамый. | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйли белү. Вакытны сорый, әйтә белү. Өйдә эшләгән эшләрне әйтә, сорый, куша белү. Эш эшләргә риза булуыңны, булмавыңны белдерү. Өй эшләрендә үзеңә булышырга, ярдәм итәргә сорый, нәрсә эшләргә кирәк икәнен әйтә белү. Кибеткә барырга куша, нәрсә алырга икәнен әйтә, сорый белү. Өйдәге эшләрне эшләргә киңәш бирә, яхшы эшләр өчен мактый белү.Өйдәге хезмәттә катнашуга карап, кешеләргә бәя бирә белү. |
| **Дуслар белән күңелле. (24 сәг.)**<br>Минем дустым бар. Дус була белү сыйфатлары. Дуслар белән итәгатьле сөйләшү. Дуслар, өлкәннәр белән телефоннан сөйләшү әдәбе. Дуслар белән туган көн үткәрү. Кибеттән ризыклар алу. Табын әзерләү. Табын янында үз-үзеңне тоту. | Дустыңның барлыгын, кемнәр белән дус икәнеңне, аларның нинди булуын әйтә белү. Кайда, кайчан дуслашкан, дусның нинди булуын, бергә нишләгәнне сөйли белү. Чын дусның авыр хәлдә калдырмавын, бер-береңә ярдәм итү турында сөйләшү. Дусларны телефоннан уйнарга чакыра, туган көнгә итагәтле чакыра белү. Дуслар белән туган көнгә әзерләнү, кибеттән ризыклар алу, кибетче белән сөйләшә белү. Татар халык ашларын, нәрсәләр ярату, яратмауны әйтә белү.Табын әзерләү турында сөйләшү. Табын янында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен сөйли белү. |
| **Дүрт аяклы дусларыбыз. (8 сәг.)**<br>Дүрт аяклы дусларның токым нары, кыяфәтләре, гадәтләре. | Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары, кыяфәтләре, гадәтләре турында сөйләшә белү. Этләр турында кызыклы мәгълүмат әйтә белү. |
| **Без спорт яратабыз. (8 сәг.)**<br>Тән әгъзалары. Табибта. Сәламәт булу кагыйдәләре. | Тән әгъзаларының исемнәрен, нәрсә авыртуын, авыртмавын табибка әйтә, сорый белү. Спорт төрләрен аера, үзеңнең нинди спорт төрен яратканыңны, нинди спорт түгәрәгенә йөргәнеңне, физкультура дәресендә нәрсә эшләгәнеңне әйтә белү. Сабантуйдагы милли уеннарны әйтә, |

| | |
|---|---|
| Спорт белән шөгыльләнү. | Сабантуйга бару, катнашу турында сөйләшү. |

**5нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның грамматик минимумы:**

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәре.
2. Тартым һәм килеш белән төрләнгән исемнәрнең берлек һәм күплек сандагы кушымчаларын аера белү.
3. Тамыр, кушма парлы, тезмә исемнәрнең ясалышы, аларның сөйләмдә кулланучын кабатлау.
4. Исемнәргә кушымчалар ялгану тәртибе.
5. Сыйфат дәрәҗәләре белән таныштыру, аларны сөйләмдә куллану.
6. Микъдар, тәртип, җыю саннарын аера белү.
7. Мин, син, ул зат алмашлыкларының, төшем килешләрендә сөйләмдә куллана белү.
8. Зат алмашлыкларының урын-вакыт килешендә сөйләмдә куллану.
9. Хәзерге заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
10. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
11. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.
12. Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта 2нче затта төрләнешен сөйләмдә куллану.
13. Фигыльнең инфинитив формасын сөйләмдә куллану.
14. Фигыльнең инфинитив формасын модаль сүзләр (кирәк, кирәкми, ярый, ярамый) белән сөйләмдә куллану
15. . **Эшләргә телим –** төзелмәсен сөйләмдә куллану.
16. **Өчен, шикелле** бәйлекләрен сөйләмдә куллану.
17. Кереш сүзләрне **(минемчә, синеңчә, билгеле, әлбәттә, беренчедән, минем фикеремчә**) сөйләмдә куллану.

**6 нчы сыйныф (105 сәг.)**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Яңа уку елы башлана (18 сәг.)** Көз җитте, яңа уку елы башлана. Бу минем мәктәбем. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә тоту. Китаплар дөньясы, китапханәгә бару, китап алу. Китапларга сак караш. | Көз вакытын сурәтли белү. Яңа уку елы башлану, аңа әзерлек, мәктәп турында сөйли белү. Уку-язу әсбапларына сак караш турында сөйләшү. Китапның ни өчен якын дус, киңәшче икәнен сөйли белү. Китапның  нәрсә турында, авторы кем икәнен әйтә белү. Китап укырга киңәш бирә белү. Китапханәгә язылу өчен анкета тутыра белү, китапханәдән үзеңә кирәкле китапны сорый, нәрсә турында икәнен сорый, сөйли белү. Китап басылу тарихы турында кыскача белешмә бирә белү. Каюм Насыйри турында кыскача мәгълүмат бирә белү. |
| **Мин - зур ярдәмче ( 21 сәг.)** Өй эшләре, өлкәннәргә булышу.  Яхшы эшләр. Дуслар белән бергә эшләү. | Өйдә нинди эшләр эшләүнең кирәклеген, нинди эшләр эшләргә яратканыңны, эшләргә теләгәнеңне, ничек булышканыңны сөйли белү. Эшне эшләргә инандыра, ышандыра  белү. Кереш сүзләрне кулланып, үз фикереңне раслый белү. Образларга бәя бирә, кешенең характер сыйфатларын әйтә белү. |
| **Дуслар белән күңелле (14 сәг.)** Минем дустым. Чын дус нинди була? Дуслык югалу. Әләкләшү, мактану – начар гадәтләр. Дуслар белән бергә ял итү. Кунакларны сыйлау. Туган көн. Төрле рецептлар. | “Дус нинди була? Ни өчен дуслашалар? Дуслар бергә нишлиләр? Минем дустым – ул нинди?”  проблемалары буенча сөйләшү. Туган көнгә өстәл әзерләү, өлкәннәргә хөрмәт турында сөйләшү. Әнинең туган көне, аңа булышу турында сөйли белү. Төрле рецептларны сөйли белү. |
| **Туган җирем - Татарстан (10 сәг.)** Туган ил, туган җир төшенчәләре. Татарстанның табигате. Татарстан республикасының дәүләт символлары. Татарстанда яшәүче милләтләр, төрле телләрдә сөйләшү. Халыклар дуслыгы. Татарстанның башкаласы Казан, аның  музейлары, театрлары. Татар сәнгатенең күренекле вәкилләре. | Туган ил, туган җир төшенчәләре турында сөйли белү. Россиядәге, Татарстандагы диңгезләрне, елгаларны, шәһәрләрне атый белү. Татарстанның табигатен сурәтли белү. Татарстан республикасының дәүләт символлары турында белешмә бирә белү. Татарстанда яшәүче милләтләр, үзеңнең милләтеңне, нинди телдә сөйләшүеңне әйтә белү.  Татарстанда халыкларның дус яшәве турында сөйли белү. Казан шәһәре турында мәгълүмат бирә белү. Татар сәнгать вәкилләренең исемнәрен әйтә белү. |
| **Табигать белән бергә (18 сәг.)** Нәрсә ул табигать? Табигатьнең безгә файдасы. Табигатьне саклау. Кошлар дөньясы. Хайваннар дөньясы. Кыргый хайваннар. Дүрт аяклы дусларыбыз. | Табигать, аның кешеләргә файдасы турында сөйләшү. Кешеләрнең урманга салган зыяны, табигатьне саклау турында киңәшләр бирә белү. Кошлар, хайваннар  тормышыннан кызыклы мәгълүматлар сөйли белү. Дүрт аяклы дусларыбызның токымнары,  кыяфәтләре, гадәтләре, аларны саклау, карау турында сөйләшү. |
| **Сәламәт тәндә – сәламәт акыл (20 сәг.)** Спорт төрләре. Спорт белән шөгыльләнү. Олимпия уеннары. Сәламәт булу кагыйдәләре. | Спорт төрләре һәм нинди спорт төрләре белән шөгыльләнү турында сөйли белү. Олимпия уеннары, кайда барлыкка килгәнен, нинди уеннар булуын, олимпия уты, олимпия флагы турында сөйли белү. Сәламәт булу өчен,  нинди кагыйдәләр үтәргә кирәклеген сөйли белү. Кешенең еш авыру сәбәпләрен әйтә, аңа авырмаска киңәшләр бирә белү. Табибта кай |

| | |
|---|---|
| | җирең авырту турында сөйләшү. |
| **Светофор – минем дустым (4 сәг.)**<br>Юлда сак булу. Юл йөрү кагыйдәләре. | Ни өчен юлда сак булырга кирәклеген әйтә белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сөйли белү. Юл йөрү кагыйдәләрен сакларга киңәш бирә белү. |

**6 нчы сыйныфны тәмамлаганда укучыларның грамматик минимумы:**

1. Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше белән танышу, текстта аңлый белү.
2. **-лык/-лек, -чы/-че** исем ясагыч кушымчалары белән таныштыру.
3. Рәвеш – сүз төркеме белән таныштыру.
4. Сорау, күрсәтү алмашлыкларын сөйләмдә тану, дөрес куллану.
5. Билгеле киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.
6. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше белән танышу.
7. Боерык фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнешен танырга өйрәтү.
8. Шарт фигыльнең барлыкта һәм юклыкта зат-сан белән төрләнеше.
9. Процессның башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын(укый башлады, укып тора, укып бетерде), теләкне (барасым килә), мөмкинлек/мөмкин түгеллекне (бара алам, бара алмыйм) белдерә торган модаль мәгънәле аналитик формалы фигыльләрнең сөйләмдә кулланылышы.
10. Белән, кебек, өчен, соң, аша бәйлекләрен исемнәр һәм алмашлыклар белән сөйләмдә кулланышы.
11. **Бәхеткә каршы, кызганычка каршы, киресенчә** кереш сүзләрен сөйләмдә куллану.

## 7 нче сыйныф (105 сәг.)

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Белем һәм тормыш (35 сәг.)** Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу. Уку-язу әсбаплары, аларны тәртиптә тоту. Яхшы уку серләре, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. | Яңа уку елындагы яңалыклар, җәйге ялны ничек уздыру, классташларыңның ничек укуы, нинди билгеләр алу, өй эшен ничек эшләү, дәрестә ничек катнашу турында сөйләшү. Начар билгегә үз карашын әйтә белү. Уку-язу әсбапларын тәртиптә тоту, яхшы уку серләре, яхшы уку өчен нинди холык сыйфатлары кирәклеге турында сөйләшү. |
| **Без бергә ял итәбез (20 сәг.)** Буш вакыт: файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы. Яшүсмерләрнең мөнәсәбәтен дә алдашу, ялганлашу. Яшьтәшләр белән бәйрәмнәрне оештыру, уздыру | Буш вакыт. Буш вакытны файдалы, файдасыз үткәрү. Яшьтәшләрнең үз-үзләрен җәмгыять урыннарында тотышы турында сөйләшү, бәя бирә белү. Яраткан шөгылең турында сөйли белү. Спорт түгәрәкләренә йөрү, спорт уеннарында катнашу, спорт чараларын, тапшыруларын карау турында сөйләшү. |
| **Өлкәннәр һәм кечкенәләр (30 сәг.)** Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәтләре. Өлкәннәрдән рөхсәт сорау. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү. | Өлкәннәр һәм кечкенәләрнең гаиләдә үзара мөнәсәбәте, кушкан эшкә җаваплы караш турында сөйләшү. Өлкәннәргә үзеңнең кая барырга, нишләргә теләгәнеңне, кайчан кайтасыңны әйтә белү, өлкәннәрдән рөхсәт сорый белү. Гаиләдә бергә бәйрәмнәр үткәрү, әти-әниләрне бәйрәм белән котлау турында сөйли белү. |
| **Без Татарстанда яшибез (20 сәг.)** Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Татар композиторы, Сара Садыйкова. | Татарстанның табигате, аның табигый байлыклары турында сөйли белү. Туган як табигатенә карата үз фикереңне белдерә белү.Татарстанның территориясе, аның географик урыны. Атаклы композитор Сара Садыйкова турында сөйли белү. |

**7 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның грамматик минимумы:**

1. Ясалышы буенча сыйфат төрләре.
2. Рәвеш төркемчәләре.
3. Теләк фигыльнең 1нче зат берлек һәм күплек сан формалары.
4. Сыйфат фигыльнең хәзерге һәм үткән заман формалары белән таныштыру.
5. Хәл фигыль белән таныштыру.
6. Исем фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.
7. Җыючы (һәм, да-да, та-та,ни...ни), каршы куючы (ләкин, ә, әмма), бүлүче (я, яки) теркәгечләре белән җөмләләр төзү күнекмәләрен системалаштыру.
8. Ияртүче (әгәр, шуңа күрә) теркәгечләрне сөйләмдә куллану.
9. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә өйрәтү.
10. Җөмләнең баш кисәкләре: ия һәм хәбәр, алар арасында сызык куелу очраклары белән таныштыру.

**8 нче сыйныф (105 сәг.)**

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Күп укыган – күп белер. (30сәг.)**<br>Классташларның укуы, билгеләр алуы, өй эшен эшләү, дәрестә катнашу.<br>Яхшы уку серләре, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар. Интернет аша үз белемеңне күтәрү. | Класташларыңның белем алуга карашын, яхшы уку өчен кирәкле сыйфатлар турында сөйли белү. Яхшы укуга карата мөнәсәбәтнеңне белдерә белү.<br>Интернет аша үз белемеңне күтәрү турында сөйләшү. Татарстан Республикасының Милли китапханәсе тарихын сөйли белү. |
| **Мин һәм минем яшьтәшләрем. (25 сәг.)**<br>Яшьтәшләрең белән аралашу. Яшьтәшләр белән аралашу кагыйдәләре. Яшьтәш ләрнең тышкы кыяфәте һәм эчке сый фатлары. Матур киенү серләре. Яраткан шөгыльләр: музыка, бию, рәсем ясау, уку һ.б. | Яшьтәшләрең белән аралашу кагыйдәләре, дуслашу серләре, нинди кызлар һәм малайлар ошавы турында сөйләшү. Яшьтәшләреңнең тышкы кыяфәтен, характер сыйфатларын әйтә белү. Матур киенү серләре турында сөйләшү.<br>Яраткан музыкаң, җырчылар, турында сөйли белү. |
| **Табигать һәм кеше. ( 30 сәг.)**<br>Табигать төшенчәсе. Бүгенге экологик проблемалар. Табигать байлыгы. Урман – кешенең якын дусты.Табигатьһәм без,табигатьтәге кызыклы күренешләр | Табигать төшенчәсе, бүгенге экологик проблемалар, табигатькә сак караш турында сөйләшү.<br>Табигать байлыгы, табигатьтәге кызыклы күренешләр турында мәгълүмат бирә белү |
| **Туган җирем – Татарстан ( 20 сәг.)**<br>Татарстанның табигате. Татарстанның башкаласы Казан, аның бүгенге йөзе: башкаладагы үзгәрешләр, спорт корылмалары, ял итү урыннары, тарихи урыннары. | Татарстанның табигате турында мәгълүмат бирә белү. Казан шәһәре, андагы яңа үзгәрешләр турында сөйли белү. Казан шәһәрендәге спорт корылмалары, ял итү урыннары, тарихи истәлекләр турында әңгәмәгә керә белү. |

**8 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның грамматик минимумы:**

1. Хикәя фигыльнең заман формаларын (хәзерге, үткән, киләчәк) сөйләмдә куллануны ныгыту.
2. Сан төркемчәләрен гомумиләштереп кабатлау.
3. Билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым алмашлыкларының сөйләмдә еш кулланыла торган очраклары белән таныштыру.
4. Сыйфат фигыльнең барлыкта һәм юклыкта заман формаларын сөйләмдә куллану.
5. Хәл фигыльне сөйләмдә куллану.
6. Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне сөйләмдә куллану.
7. Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне сөйләмдә куллану.
8. Гади фигыль хәбәрле (Мин татарча беләм), исем хәбәрле (Безнең гаиләбез тату) һәм тезмә фигыль хәбәрле (Мин укырга яратам) гади җөмләне таный, аера белү.
9. Тиңдәш кисәкле җөмләләрне таный, аера белү.

**9 нчы сыйныф (68 сәг.)**

10.

| Предмет буенча билгеләнгән тематик эчтәлек, якынча сәгатьләр саны | Тема буенча предмет нәтиҗәсе, коммуникатив максат |
|---|---|
| **Без Татарстанда яшибез. ( 25 сәг.)** Татарстан турында гомуми белешмә. Татарстан Республикасының мәйданы, табигате, шәһәрләре, анда яшәүче милләтләр. Татарстанның икътисади үсеше. Татар музыка сәнгате. Татар театр сәнгате, аның тарихы, бүгенге торышы. Татарстанда чыга торган газета-журналлар | Татарстан турында гомуми белешмә бирә белү: Татарстан Республикасының мәйданы, табигате, шәһәрләре, анда яшәүче милләтләре, Татарстан дәүләтенең символлары, аларның авторлары турында сөйли белү. Татарстан промышленносте продукцияләре турында әңгәмәгә керә белү. Харис Якупов иҗаты турында сөйли белү. Татар музыка сәнгате вәкилләре: Александр Ключарев, София Губәйдуллина, Салих Сәйдәшев турында әңгәмә кора белү. Татар театр сәнгате барлыкка килү турында белешмә бирә белү. Тормышыбызда театр роле турында фикер алышу. Татарстанда чыга торган газета-журналлары турында белешмә бирә белү |
| **Һөнәр сайлау. (20 сәг.)** Төрле һөнәр ияләренең хезмәте. Хезмәт базарындагы ихтыяҗ. Яшүсмерләрнең эшкә урнашуы. Белем алу һәм тормышта үз урыныңны табу проблемасы. Үз гаилә члennарының профессияләре. Төрле профессияләргә хас сыйфатлар. Үзеңә ошаган профессия. Үзең яшәгән төбәктәге колледжлар, техникумнар, аларда әзерләнә торган һөнәрләр | Төрле һөнәр ияләренең хезмәте, хезмәт базарындагы ихтыяҗы булган һөнәрләр турында әңгәмә кора белү. Яшүсмерләрнең эшкә урнаша алу вакыты, рөхсәт ителгән хезмәт төрләре турында сөйләшү. Уңышлы һөнәр сайлау шартлары турында әңгәмә кора белү. Гаилә әгъзаларының һөнәрләре, төрле һөнәрләргәгә хас сыйфатлар турында фикер алышу. Үзеңә ошаган профессияне яклый белү. Үзең яшәгән төбәктәге колледжлар, техникумнар, аларда әзерләнә торган һөнәрләр, уку үзенчәлекләре турында белешмә бирә белү. |
| **Сәламәтлек – зур байлык ( 8 сәг.)** Сәламәт яшәү рәвеше. Спорт белән шөгыльләнү. Дөрес туклану. Зарарлы гадәтләр, алардан ничек котылырга? Гаджетомания. | Сәламәт яшәү кагыйдәләре, сәламәтлекне саклау өчен кирәк булган чаралар, спорт белән шөгыльләнергә кирәклеге турында сөйләшү. Зарарлы гадәтләр, аларны булдырмау, алардан котылу юллары турында сөйли белү. “Зарарлы гадәтләрдән тыш яшәү – заманча яшәүме?” проблемасы буенча әңгәмә кора белү. Кәрәзле телефон, плеерларны куллану, компьютер уеннары, аларга бәйлелек турында сөйләшү |
| **Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый. ( 15 сәг.)** Бөек Ватан сугышы. Татарстанның Советлар Союзы геройлары. Муса Җәлил һәм Андре Тиемрманс. Моабит дәфтәрләре. Җәлилчеләр. 9нчы Май – Җиңү көне. Бөек Ватан сугышында катнашкан өлкән буын-ветераннарына хөрмәт | Бөек Ватан сугышы турында белешмә бирә, 9нчы Май – Җиңү көне турында сөйли белү. Татарстан уллары һәм кызлары – Советлар Союзы геройлары: Муса Җәлил, җәлилчеләр, Мәгубә Сыртланова, Газинур Гафиятуллин турында әңгәмә кора белү. Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар, аларга хөрмәт күрсәтү турында сөйләшү |

11. .

**9 нчы сыйныфны тәмамлаганда укучыларның грамматик минимумы:**

1. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, аларга сорау куя,аера белү.
2. Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә өйрәтү.
3. Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру.

4.Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.

4. Иярчен хәл җөмләләрнең **иярчен урын җөмлә, вакыт җөмлә, сәбәп җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, кире җөмләләре** белән таныштыру һәм аларны сөйләмдә урынлы кулланылуына ирешү.
5. Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куя һәм аларны тиешле интонация белән әйтә белү.

**Укытуның материаль-техник һәм мәгълүмати тәэмин ителеше**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган "Рус мәктәпләрендәге рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын укыту гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты".
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән "Төп гомуми белем бирү мәктәбенең рус телендә сөйләшүче балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы", төзүче-авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л. Малафеева. – Казан, 2014.
3. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмаларында татар теле укыту. 5нче сыйныф (Укытучылар өчен методик кулланма). – Казан, "Татармультфильм", 2014.
4. Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М. Гомуми белем бирү оешмаларында рус телле балаларның татар теленнән белемнәрен контрольгә алу буенча биремнәр җыентыгы. – Яр Чаллы, 2014.
5. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан, "Мәгариф", 2008.

**Өстәмә әдәбият**

1. Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту, 5нче сыйныф. Авторлары: Р.З.Хәйдәрова, Л.Ә. Гыйниятуллина, Г.И.Газизуллина. – Казан, "Татармультфильм", 2014.
2. Фатыйхова Р.Н. Татар теленнән диктантлар, контроль эшләр, тестлар. – Казан, "Гыйлем" нәшрияты, 2009.
3. Насибуллина Р.Н. "Татарский язык в таблицах и схемах для русскоязычных уча- щихся начальных классов". – "Мәгариф" нәшрияты, 2007.
4. Максимов Н.В. "Урта мәктәптә татар теле укыту: Фонетика. Морфология."Укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: "Мәгариф" нәшрияты, 2004.5.

5. “Фән һәм мәктәп”, “Мәгариф” журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары.

**Мәгълүмат чыганаклары**

http://www.ed.gov.ru

Белем бирү буенча федераль агентлык

http://www.apkppro.ru РФ мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм профессиональ әзерләү академиясе

http://www.lexed.ru Федеральный центр образовательного законодательства http://www.rustest.ru Федераль тест үткәрү үзәге

http://www. tatedu.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы

http://www.edu. kzn.ru ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Белем порталы http://www.mon.tatar.ru

http://www.shoolexpo.ru http://. belem.ru

http://. tatar.ru ТР рәсми серверы

http://. Tat. Tatar - inform.ru ТР мәгълүмат агентлыгы http://. intertat.ru ТР электрон газетасы

http://. xat.ru Татар хат алышу хезмәте http://. suzlek.ru on- line русча сүзлек

http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе http://. Tatar.com.ru татар теле сүзлекләр һәм үзәйрәткечләр

http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар

http://. tataroved.ru Татар тарихы: төрки – татар дөньясы http://. selet.ru “Сәләт” яшьләр

http://. Kitapxane.at.ru татар телендәге әдәби әсәрләр китапханәсе http://. Tatarca.boom.ru татарча текстлар

Кушымта№2

Татар теле, 2016-2017 нче уку елы
Укытучы: Чекашова Г.Ф.

**ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**
**5 нче сыйныф**

| № | Дәрес темасы | Укучы эшчәнлегенә характеристика | Предмет нәтиҗәләре | Көтелгән нәтиҗәләр | | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Метапредмет нәтиҗәләре | Шәхси нәтиҗәләр | план | факт |
| **I чирек (27 сәгать)<br>Без мәктәптә. 22 сәгать** | | | | | | | |
| 1 | Син алмашлыгын юнәлеш һәм төшем килешләрендә куллану | Укытучы аңлатуы, әңгәмә,күнегүләр эшләү | Исәнләшү, саубуллашу, комплимент әйтү өчен кулланыла торган сүзләр | **Регулятив:** эшләнлек өчен эш урынын әзерләү.<br>**Танып белү**: фикерләрне логик чылбырга салу.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Шәхес ара һәм мәдәни ара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 2 | Исемнәрнең төшем, юнәлеш килешләрендә төрләнүе | Укытучы аңлатуы, әңгәмә,күнегүләр эшләү | Уку-язу әсбапларының атамалары: шакмаклы, буйлы, кирәк, кирәкми | **Регулятив:** укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү.<br>**Танып белү**: аңлап уку, тиешле мәгълүматны сайлап алу.<br>**Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | Шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 3 | С/ү. Татарстан | Дәреслек белән | Мәктәптә белем | **Регулятив**: | Әхлакый | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | дәүләт гимны төзелмәсе | эш,өлешчә эзләнү | бәйрәме турында сөйли белә. Россиянең, Татарстанның дәүләт гимны турында сөйләшү | эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү**: аңлап уку; тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 4 | Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше | Алфавит буенча су-зык һәм тартык авазларны искә төшерү, күнегүләр эшләү | Минем мәктәбемдә төзелмәсен сөйләмдә дөрес куллану. Контроль эштә хата барлыгын, хата юклыгын әйтә белү | **Регулятив:** Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү, укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** Аңлап уку, тиешле мәгълүматны сайлап алу, төп мәгълүматны аеру, фикерләрне логик чылбырга салу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү. | Әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм героиларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларынан чыгып бәя бирә белү | | |
| 5 | Исемнәрнең күплек санда тартым белән төрләнеше | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү | Исемнәрең күплек санда тартым белән төрләнешен сөйләмдә дөрес куллану | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү; билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** аңлап уку; тиешле мәгълүматны сайлап алу **Коммуникатив:** | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү. | | | |
| 6 | Боерык фигыль | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү | Эшлә, чиш, укы, сөйлә, кара, тыңла, яса, тор, кер, тарат. Боерык фигыль 2 зат берлек һәм күплек саннарда куллана белү | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** төп мәгълүматны аеру; фикерләрне логик чылбырга салу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучанлык хисләрен тәрбияләү | | |
| 7 | Әдәпле сөйләм формалары | Грамматик биремле эш | Әйт әле, әйтче, әйтегез, әле төзелмәләрен сөйләмдә куллану | **Регулятив:** билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү; эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата төземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 8 | Исемнәр ясалышы. Кабатлау | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | Китапны кадерләп тоту турында киңәш бирә белү. Китапның киңәшче, дус икәнен раслап сөйли белү. Китапханәдә китапханәче белән китап алу турында сөйләшү | **Регулятив :** эшләнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив :** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | Шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 9 | Кереш контроль эш | Грамматик биремлем контроль эш | Башлана, бетә, контроль эш, мәсьәлә, мисал, эшли, чишә, кайта, сорый, укыта. Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында сөйләмдә куллану | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү :** тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 10 | Хаталар өстендә эш. Күнегүләр эшләү | Хаталар өстендә күнегүләр эшләү, чагыштыру | Башлана, бетә, контроль эш, мәсьәлә, мисал, эшли, чишә, кайта, сорый, укыта. Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында сөйләмдә куллану | **Регулятив:** билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | Әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм героиларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларынан чыгып бәя бирә белү | | |
| 11 | Хәзерге заман хикәя фигыльне | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, | Башлана, бетә, контроль эш, мәсьәлә, | **Регулятив** : укытучы ярдәме белән | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | барлык формасында зат-сан белән төрләнеше | чагыштыру | мисал, эшли, чишә, кайта, сорый, укыта | максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** аңлап уку, тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |
| 12 | Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында зат-сан белән төрләнеше. Күнегүләр эшләү | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Башлана, бетә, контроль эш, мәсьәлә, мисал, эшли, чишә, кайта, сорый, укыта. Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында сөйләмдә куллану | **Регулятив:** эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү. | Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучанлык хисләрен тәрбияләү | | |
| 13 | Хәзерге заман хикәя фигыльне юклык формасында сөйләмдә куллану | Грамматик биремле эш | Хәзерге заман хикәя фигыльне юклык формасында сөйләмдә куллану | **Регулятив:** укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү; эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |
| 14 | Хәзерге заман | Укытучы аңлатуы, | Хәзерге заман хикәя | **Регулятив:** | Шәхесара һәм | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хикәя фигыльне юклык формасында сөйләмдә куллану. Күнегүләр эшләү | әңгәмә,күнегүләр эшләү, диалог төзү | фигыльне юклык формасында сөйләмдә куллану. | эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 15 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Укытучы аңлатуы, әңгәмә,күнегүләр эшләү | Бүген, иртәгә, мөстәкыйль эш, вакыт, озак, кызыклы, чирек азагы. Сүзләрне сөйләмдә куллана белү; хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлекне сөйли белү. | **Регулятив:** эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** аңлап уку; тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 16 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль. Күнегуләр эшләү | Дәреслек белән эш,өлешчә эзләнү | Бүген, иртәгә, мөстәкыйль эш, вакыт, озак, кызыклы, чирек азагы | **Регулятив:** укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; | Әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм героиларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларынан чыгып бәя бирә белү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | | | |
| 17 | -мы/-ме сорау кисәкчәләре | Алфавит буенча су-зык һәм тартык авазларны искә төшерү, күнегүләр эшләү | Өй эше эшләү турында сөйләшү. Олегка бәя бирә белү. Уенга чакыра белү. | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү; билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** аңлап уку; тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |
| 18 | Контроль күчереп язу. Сан төркемчәләре | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү | Кушарга, алырга, тапкырларга, бүләргә, чишәргә, рәт, бүлмә, мисал, мәсьәлә | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** төп мәгълүматны аеру; фикерләрне логик чылбырга салу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү; әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучанлык хисләрен тәрбияләү | | |
| 19 | Сан төркемчәләре. Күнегуләр эшләү | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү | Дистәләр һәм йөзләр эчендәге саннарны сөйләмдә куллана белү. Дәресләр расписаниесен әйтә белү. Үзе турында саннар кулланып, | **Регулятив:** билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү; | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мәгълүмат бирә белү. | эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү.<br>**Коммуникатив:**<br>әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү | | | |
| 20 | Чөнки, ләкин теркәгечләре | Грамматик биремле эш | Җиңел, авыр, өтер, нокта, сорау, төшеп калган, тикшерде, хаталы, хатасыз. Чөнки, ләкин теркәгечләрен сөйләмдә куллану. Дәрестә диктант язу турында сөйләшү. | **Регулятив:**<br>эшләнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү.<br>**Танып белү:**<br>иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру.<br>**Коммуникатив:**<br>әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төз | Шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 21 | “Без мәктәптә” темасын кабатлау | Аңлату, әңгәмә, күнегүләр эшләү | Урын җыям, сөртәм, юынам, иртәнге аш ашыйм, барам, кайтам, алам. Шигырь героеның һәм үзеңнең иртәнге режимың турында сөйли белү. Геройга бәя бирә белү. | **Регулятив:**<br>уку эшчәнлеген оештыра белү.<br>**Танып белү:**<br>тиешле мәгълүматны сайлап алу.<br>**Коммуникатив:**<br>әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| 22 | “Без мәктәптә” темасы буенча контроль эш. | Әңгәмә,укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү | Шигырь героеның һәм үзеңнең иртәнге режимың турында сөйли белү. Геройга бәя бирә белү. | **Регулятив:**<br>билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү.<br>**Танып белү:**<br>эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү. | Әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм героиларның гамәлләренә гомумкешелек нормаларынан | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | чыгып бәя бирә белү | | |
| **Мин өйдә булышчы. (29 сәгать).** | | | | | | | |
| 23 | Хаталар өстендә эш. Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында зат-сан белән төрләнеше | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Сәгать җиде, сәгать җидедә, нәкъ сәгать җидедә, көндезге җидедә, көндезге бердә, дәресләрдән соң, сәгать җиденче яртыда. Көндәлек режимны сөйли белү | **Регулятив:** эшләнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төз | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата төземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү | | |
| 24 | Хәзерге заман хикәя фигыльне барлык формасында зат-сан белән төрләнеше | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Чүп чыгара, тузан сөртә, кер үтүкли, идән себерә, сеңлесен карый, тузан суырта, ашарга әзерли. Хәзерге заман һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык, юклык формаларын кулланып, өй хезмәте турында сөйләшү | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучанлык хисләрен тәрбияләү | | |
| 25 | Сәгать ничә, сәгать ничәдә? | Укытучы аңлатуы, күнегүләр эшләү, чагыштыру | Хәзерге заман һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык, юклык формаларын | **Регулятив:** билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү. **Танып белү:** | “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата төземлелек” төшенчәләрен кабул | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | кулланып, өй хезмәте турында сөйләшү | эшчәнлек процессында контроль һәм бәя бирү. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү | итү, аларның кадерен белү | | |
| 26 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль | Грамматик биремле контролъ эш | Хәзерге заман һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык, юклык формаларын кулланып, өй хезмәте турында сөйләшү | **Регулятив:** эшләнлек өчен эш урынын әзерләү; укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. **Танып белү:** иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. **Коммуникатив:** әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төз | Шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләген формалаштыру | | |
| 27 | Билгеле үткән заман хикәя фигыль. Күнегүләр эшләү | Хаталар өстендә эш. Укытучы аңлатуы, әңгәмә,күнегүләр эшләү, диалог төзү | Хәзерге заман һәм билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлык, юклык формаларын кулланып, өй хезмәте турында сөйләшү | **Регулятив:** уку эшчәнлеген оештыра белү. **Танып белү:** тиешле мәгълүматны сайлап алу. **Коммуникатив:** әңгәмәдәшнең аралашу эшчәнлеге белән идарә итү | Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау | | |
| **II чирек (21 сәгать)** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
